# ҖИР АСТЫНДА ЮЛЛАР ЮК

Рәүф Сәлтәшев көе

(Эльмир Газизуллин репертуарыннан)

Кем иртәрәк, кем соңрак...
Беркем мәңгелек түгел.
Барыбыз да бер китәбез
Калдырып дөнья йөген.

*Кушымта:*
Дөньялыкта җырлап, гөрләп,
Күреп-күрешеп калыйк.
Күрешергә, йөрешергә
Җир астында юллар юк.

Даһига да, җаһилга да
Мәрхәмәтле Җир-ана,
Куенында һәр кемнә
Өч аршынлап җир таба.

*Кушымта.*

Санаулы гомер сәгате,
Яшәп калырга ашык.
Күрешергә, йөрешергә
Җир астында юллар юк.

*Кушымта.*